ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 12.10.2023 КАРАР
1517

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары булып торучы һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре бюджет керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Тәртибен раслау турында» 2011 елның 26 июнендәге 418 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясы нигезендә һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә норматив хокукый базаны Россия Федерациясенең гамәлдәге бюджет законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары булып торучы һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре бюджет керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Тәртибен раслау турында» 2011 елның 26 июнендәге 418 номерлы карарына үзгәрешләр кертеп, Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнары булып торучы һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре бюджет керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Тәртибен, әлеге карарга теркәлгән 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Җитәкче Э.Р. Әхмәдиева

Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
12.10.2023 1517
номерлы карарына 1 кушымта

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары булып торучы һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре бюджет керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары булып торучы һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре бюджет керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Тәртибе (алга таба - керемнәрнең баш администраторлары) бюджет вәкаләтләрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгели.

2. Баш керем администраторлары исемлеге һәм аларга беркетелә торган керем кодлары Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турындагы карары белән раслана.

3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре бюджеты керемнәренең баш администраторлары сыйфатында:

а) Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәре администраторлары исемлеген формалаштыралар һәм раслыйлар;

б) Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына түбәндәге документларны формалаштыралар һәм тапшыралар:

- Алабуга муниципаль районы бюджетының административ керемнәрен бәяләүне һәм фаразлауны;

- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән срокларда административ керемнәр буенча бюджеты үтәлеше буенча аналитик материалларны;

- Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджеты проектын төзү өчен кирәкле белешмәләрне;

- касса планын төзү һәм алып бару өчен кирәкле белешмәләрне;

в) гамәлдәге законнарда һәм башка хокукый актларда билгеләнгән формалар һәм сроклар буенча керемнәрнең баш администраторының бюджет хисабын төзиләр һәм тапшыралар;

г) гамәлдәге законнарда билгеләнгән таләпләр нигезендә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетына административ керемнәр керүне фаразлау методикасын раслый;

д) Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән очракларда, Алабуга муниципаль районы бюджеты керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында кабул ителгән хокукый актларга ярашлы рәвештә, бюджет ке[illegible] администраторы вәкаләтләрен башкара.

4. Ведомство буйсынуындагы администраторлар булмаган очракта, Алабуга муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторы түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

- бюджетка түләүләрнең, алар буенча пеняларны һәм штрафларны хисаплауның дөреслеген, тулылыгын һәм вакытында башкарылуын исәпләүне, исәпкә алуны һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

- Алабуга муниципаль районы бюджетына түләүләр буенча бурычларны, пенялар һәм штрафлар түләтүне гамәлгә ашыра;

- бюджетка артык түләнгән (түләтелгән) түләүләрне, пеняларны һәм штрафларны, шулай ук мондый кайтаруны вакытында башкармаган өчен процентларны һәм артык түләнгән суммаларга исәпләнгән процентларны кайтару турында карар кабул итә һәм Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә кайтаруны гамәлгә ашыру өчен Федераль казначылык органына йөкләмә тапшыра;

- Алабуга муниципаль районы бюджетына түләүләрне исәпләү (төгәлләштерү) турында карар кабул итә һәм Федераль казначылык органына хәбәр итә;

- Алабуга муниципаль районы бюджеты керемнәренең тиешле баш администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләрне һәм бюджет хисаплылыгын формалаштыра;

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасына дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр өчен физик һәм юридик затлар тарафыннан акчаларны, шулай ук Алабуга муниципаль районы бюджеты керемнәрен формалаштыру чыганагы булган башка түләүләрне түләү өчен кирәкле мәгълүматны тапшыралар;

- бюджетка түләүләр буенча бурычны түләттерү өметсез дип тану турында кабул итә;

- Бюджет кодексы һәм аңа ярашлы рәвештә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган норматив-хокукый актлар (муниципаль хокукый актлар) белән билгеләнгән башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

5. Бюджет керемнәренең баш администраторлары үз карамагындагы казна учреждениеләренә бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру һәм аларга вәкаләтләр бирү тәртибен раслыйлар һәм җиткерәләр, ул түбәндәге нигезләмәләрне үз эченә алырга тиеш;

а) административ вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы керемнәр чыганакларын Алабуга муниципаль районы бюджеты керемнәре администраторларына беркетү, әлеге түләүнең төрен администрацияләү өчен нигез булып торучы Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм Алабуга муниципаль районы норматив хокукый актларын күрсәтеп. Керем чыганаклары исемлеген төзегәндә аларны детальләштерүгә бәйле үзенчәлекләрне чагылдырырга кирәк;

б) Алабуга муниципаль районы бюджеты керемнәре администраторларына, Алабуга муниципаль районы бюджетының аларга беркетелгән керем чыганакларына карата, түбәндәге бюджет вәкаләтләрен бирү:

- бюджетка түләүләрне, пеняларны һәм штрафларны башкаруны
һәм үз вакытында башкарылуын исәпләү, исәпкә алу һәм контрольдә то

Документ создан в электронной форме. № 1517 от 12.10.2023. Исполнитель: Мусина Е.А.
Страница 3 из 6. Страница создана: 05.12.2023 16:22
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

- Алабуга муниципаль районы бюджетына түләүләр буенча бурыч, пенялар һәм штрафлар түләтү;

- бюджетка артык түләнгән (түләтелгән) түләүләрне, пеняларны һәм штрафларны, шулай ук мондый кайтаруны вакытында башкармаган өчен процентларны һәм артык түләтелгән суммаларга исәпләнгән процентларны кайтару турында карарлар кабул итү һәм Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә кире кайтаруны гамәлгә ашыру өчен Федераль казначылык органына йөкләмә тапшыру;

- Алабуга муниципаль районы бюджетына түләүләрне исәпләү (төгәлләштерү) турында һәм Федераль казначылык органына тиешле хәбәрнамә бирү турында карар кабул итү;

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртип нигезендә, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасына дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр өчен физик һәм юридик затлар тарафыннан акчаларны, шулай ук бюджеты керемнәрен формалаштыру чыганагы булган башка түләүләрне түләү өчен кирәкле мәгълүматны тапшыралар;

в) Алабуга муниципаль районы бюджетының административ керемнәре буенча беренчел документларны тутыру (төзү) һәм бюджет исәбендә чагылдыру тәртибен билгеләү яки әлеге мәсьәләләрне җайга сала торган норматив хокукый актларны күрсәтү;

г) Алабуга муниципаль районы бюджетының административ керемнәренең бюджет исәп хисабы мәгълүматларын чагыштыру тәртибен һәм срокларын билгеләү;

д) Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, шул исәптән Россия Федерациясе Финанс министрлыгының норматив хокукый актлары нигезендә ачыкланмаган кертемнәрне төгәлләштергәндә Алабуга муниципаль районы бюджеты керемнәре администраторларының гамәлләре тәртибен билгеләү;

е) Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, Алабуга муниципаль районы бюджеты керемнәрен түләтүчедән бюджетка түләүләрне, алар буенча пеняларны һәм штрафларны суд органнары аша яки суд приставлары аша мәҗбүри рәвештә түләткәндә керем администраторларының гамәлләре тәртибен билгеләү (шул исәптән Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, шул исәптән Россия Федерациясе Финанс министрлыгының, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының норматив хокукый актлары нигезендә судка (җәмәгать судьясына) һәм (яки) суд пристав-башкаручыга түләү документын тутыру өчен кирәкле мәгълүмат исемлеген билгеләү);

ж) керемнәр администраторының структур бүлекчәләре арасында мәгълүмат алмашу тәртибен билгеләү, шул исәптән Алабуга муниципаль районы бюджеты керемнәре администраторы кабул иткән финанс йөкләмәләре һәм Алабуга муниципаль районы бюджетына түләүләрне төгәлләштерү (кире кайтару) турындагы карарлар турында мәгълүмат алмашуны тәэмин итү;

з) Россия Федерациясе Министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән керем администраторлары тарафыннан бюджетка түләүләр буенча дебитор бурычларын,аларга пенялар һәм штрафлар түләтү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру регламентын билгеләү таләбе.

6. Алабуга муниципаль районы бюджеты керемнәре администра


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары нигезендә Федераль казначылык органына бюджет керемнәрен администрацияләү буенча операцияләрне исәпкә алу өчен шәхси счетлар ачалар.

7. Алабуга муниципаль районы бюджеты керемнәренең Баш администраторлары составы һәм (яки) функцияләре үзгәргән вакытта, аларны идарә итү вәкаләтләре бирелгән керемнәрнең баш администраторы әлеге мәгълүматны Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына күрсәтелгән очраклар башланганнан соң биш эш көне эчендә җиткерә. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы Алабуга муниципаль районы бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлегенә, шулай ук аларга беркетелгән бюджет керемнәрен классификацияләү кодлары составына үзгәрешләр кертү өлешендә карар проекты әзерли. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты керемнәрнең Баш администраторлары вәкаләтләрен керемнәрнең Баш администраторлары исемлегенә, шулай ук аларга беркетелгән бюджет керемнәрен классификацияләү кодлары составына үзгәрешләр кертү өлешендә гамәлгә ашыру турында карарны раслый һәм керемнәрнең баш администраторларына җиткерә.

8. Дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлар булган документларны формалаштыру Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы законнарына ярашлы рәвештә башкарыла.

Лист согласования к документу № 1517 от 12.10.2023
Инициатор согласования: Мусина Е.А. Главный специалист организационного отдела
Согласование инициировано: 05.12.2023 16:23

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано 05.12.2023 - 19:21 | - |